ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 85-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 85-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 298-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**Татарстан Республикасы**
**ЗАКОНЫ**

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 10 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 48 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), «2026 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

**Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен билгеләнгән ташламалы салым ставкаларының гамәлдә булуын озайтуны күздә тота.

Коммерциягә карамаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтләренә, шулай ук гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яисә дача хуҗалыгы алып бару өчен 2019 елның 1 гыйнварга кадәр төзелгән коммерциягә карамаган оешмаларга мөнәсәбәттә гомуми файдаланудагы мөлкәт булып торучы мөлкәткә салым салудан 2027 елның 1 гыйнварына кадәр азат итүне озайту каралган. Салым ташламасы социаль һәм бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән.

Сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт ихтыяҗлары өчен файдаланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына караган оешмалар өчен, федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан финанслана торган оешмалардан тыш, халыкның медицина ярдәме сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсен үстерү һәм физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүче кешеләр санын арттыру максатларында салымның исәпләп чыгарылган бәясеннән 4,55 процент күләмендә салым түләү рәвешендә билгеләнгән преференцияләрне 2027 елның 1 гыйнварына кадәр озайту күздә тотыла.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.

Коммерциягә кармаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтләренә һәм сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт ихтыяҗлары өчен файдаланыла торган социаль-мәдәни өлкә объектларына карата салым преференцияләре суммасы якынча 189,3 млн.сум дип бәяләнә.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.